*Единство в многообразии*

# ФИКЕР

**Орган Казахстанского конгресса татар и башкир**

**№1 (114) 2018 ел**

**Газета «Фикер» выходила в 1905-1907 гг. при участии Габдуллы Тукая. С 1993 г. выходит в г. Алматы: с 2000 г. под названием «Фикер-Өмет», с 2013 г.«Фикер».**



***Кадерле дуслар!***

***Яңа 2018 ел белән Сезне ихлас күңелдән котларга рөхсәт итегез! Яңа елда Сезгә һәм якыннарыгызга сәламәтлек, гаиләләрегездә татулык һәм тынычлык, тормышыгызда, эшегездә яңа уңышлар телим.***

***Халкыбызга бердәмлек һәм хәерле нәтиҗәләр телим!***

***Яңа ел белән!***

***Ихтирам белән***

***Тәүфик Кәримов, Казакъстан татарлары***
***һәм башкортлары конгрессының рәисе***



**ЯҢА ЕЛ**

Уза еллар аккан сулар кебек,
Алдагысы- гүя яңа елга...
Ә елгалар бүген боз астында,
Ташып агар язын Яңа елда.

Яңа елда ак бураннар дулар,
Кар астыннан калкыр умырзая.
Яңа елда җанда сорау туа:
«Үтмәгәнме гомер, -диеп,-зая?»

Язмыш елгасына башын салып,
Ага еллар, ага дәрьяларга.
Яңа елда хыяллана кеше,-
Яши башлар сыман өр-яңадан.

Яңа елда, могҗизалар көтеп,
Оран салам сезгә, карабайлар!-
Яңа елда, бәлки, берәрегез
Милләт зарын илдә бер абайлар...

Яңа елның яңа таңы ата,-
Йоклаганнар кайчан уяныйрлар?
Кайчан узар салкын урыс кышы?
Милли булыр кайчан миллионерлар?

Киләсе ел гүя, бәхет тулып,
Ага торган шаулы яңа елга.
Шул елгада коеныйрга язсын
Һәммәбезгә Яңа килгән елда!

***Разил Вәлиев***

***Фикер №1, 2018 ел***

*Хөрмәтле Гриф әфәнде!*

*Соңгы арада Татарстан Дәүләт Советы депутатларын, туган телебезне якламауда гаепләп, интернетта төрле язмалар пәйда булды. Мин бөтен депутатлар өчен дә җавап бирә алмыйм, әмма бу мәсьәләдә катгый фикеремне белдереп, һәр сессиядә диярлек чыгыш ясавымны сезгә дә искәртергә булдым. Әллә белмичә, әллә белеп тә кемнәрдер котыртуы беләнме, мондый имеш-мимеш сүзләр сөйләү һәм гайбәт тарату һич кенә дә милләтебез файдасына түгел. Бу мәсьәлә мине, гомерем буе милләтебез һәм туган телебез өчен ут йотып яшәгән кеше буларак, бик нык рәнҗетә. Сүземне озынга сузмыйча, Дәүләт Советының ноябрь аенда телгә багышланган соңгы сессиясендә ясаган чыгышымны җибәрәм.*

**ЧЫГЫШ**

Хөрмәтле Президент!
Хөрмәтле Дәүләт Советы Рәисе!
Хөрмәтле Дәүләт Киңәшчесе!
Хөрмәтле депутатлар һәм сессия эшендә катнашучылар!

Беркемгә дә сер түгел, бүген Татарстан мәктәпләре таяк тыгып болгаткан кырмыска оясына охшап калды. Сәбәбе бер генә – киләчәктә татар телендә укыту, татар телен һәм әдәбиятын өйрәнү ничек булыр, гомумән, татар милләтенең язмышы кайсы якка таба борылыр? Бу мәсьәлә бүген ата-аналарны, укытучыларны, мәгариф хезмәткәрләрен генә түгел, республикада яшәүче миллионлаган кешене борчуга салды. Язучылар, мәдәният-сәнгать әһелләре даирәсендә генә түгел, кая гына барма, шунда тел мәсьәләсе турында ярсый-ярсый сөйләшәләр, безгә көне-төне

шалтыраталар, хатлар язалар, имзалар җыялар, социаль челтәрләр аша мөрәҗәгать итәләр.

Югыйсә, Россия законнарында туган телләрне һәм республика дәүләт телләрен укыту мөмкинлеге турында бик ачык итеп язылган. Әмма ул законнарны гамәлгә ашыру механизмы Россия мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан төгәл һәм җентекле итеп эшләп бетерелмәгән. Шул сәбәпле мәгариф системасында телләр укыту буенча аңлашылмаучанлыклар, буталчыклар килеп чыккан...

Шул төгәлсезлек аркасында бүген меңләгән укытучыларыбызның төн йокылары качты, бер гаепсез мөгаллимнәребезнең язмышы бүген кыл өстендә, аларны эштән китәргә, дәресләрен киметергә мәҗбүр итәләр, куркыталар, яныйлар...

Шушы яшькә җитеп, минем әле милли мәгариф өлкәсендә мондый вәхшилекне, мондый башбаштаклыкны күргәнем юк иде. Шушы көнгә кадәр минем прокурорларны эшкә җигеп, иң тупас рәвештә халыкны телсез калдыру өчен аяусыз көрәш барганын ишеткәнем юк иде.

Урысның бөек мәгърифәтчесе Константин Дмитриевич Ушинский заманында: “Милли мәгариф системасы, милли мәктәбе булмаган милләтнең киләчәге юк”, – дип әйткән булган. Димәк, шулай итеп, кемнәрдер безнең халыкны киләчәксез калдырырга, үлемгә хөкем итәргә җыена микән әллә? Телсез, мәдәниятсез, сәнгатьсез бер милләтнең дә милләт була алмавы, әкренләп юкка чыгуы беркемгә дә сер түгел. Кеше гомеренә кул салу һәр җәмгыятьтә иң зур җинаять санала, ә шул ук кешеләрдән торган милләтнең язмы-шына кул салу – коточкыч җинаятьтер.

Ничәмә-ничә гасырлар буе канлы яулар, тарих афәтләре кичеп, патшасыз, дәүләтсез чакта да сакланып калган татар теле ни өчен әле менә бүген республикабыз аякка басып килгән чорда, юкка чыгарга тиеш? Без моның белән килешә алмыйбыз, без моның белән килешсәк, әби-бабаларыбыз, халкыбыз алдында җинаятьчеләр булыр идек.

Татар телендә иҗат иткән шигырьләре өчен 17 ел буе ГУЛАГ лагерьләрендә иза чиккән бөек татар шагыйре Хәсән Туфан иреккә чыккач, болай дип язган иде:

*Гасырларны кичте, исән калды*
*Туган телебез булган бу алмаз.*
*Чабаталы чакта югалмады, –*
*Татарстанлы чакта югалмас.*
*Югалмас!*

Әйе, Ходай Тәгалә тарафыннан бирелгән, мең еллар буена буыннан буынга күчеп, сакланып килгән иң зур рухи байлыгыбыз – туган телебезне саклау һәм киләчәк буыннарга тапшыру безнең изге бурычыбыз. Һәм туган телебезне, милләтебезнең рухын, җанын куркыныч астына куярга, аны кимсетергә һәм мыскылларга беркемнең хакы юк.

Мин кичә генә Дагыстан башкаласы Махачкалада нәкъ менә шушы мәгариф проблемаларына, милли мәгариф һәм телләр язмышына багышланган бөтенроссия киңәшмәсендә катнашып, чыгыш ясап кайттым. Россия Дәүләт Думасы оештырган бу киңәшмәдә катнашучы милли республика вәкилләре һәммәсе дә безнең кебек үк үз телләренең язмышлары өчен борчыла. Димәк, бу проблема бүгенге көндә бер безне генә түгел, һәммә халыкны да борчуга салган. Ә бу үтә катлаулы проблеманы куркыту-янау юлы белән түгел, ә түгәрәк өстәл

янына утырып киңәш-табыш итеп бик саклык белән хәл кылырга кирәк иде.

Халык безгә бертуктаусыз мөрәҗәгать итә, сайлаучыларыбыз хәтта тел мәсьәләсендә республикада референдум үткәрүне дә таләп итәләр. Без – депутатлар, мондый шартларда авызыбызга су кабып, гаҗәпләнеп, баш чайкап кына утыра алмыйбыз.

Россия Конституция судының Татарстанның ике дәүләт телен – татар һәм рус телләрен бертигез күләмдә укыту турындагы законнары Россия Конституциясенә каршы килми, дигән карары бар. Тагын нәрсә җитми, тагын нәрсә кирәк?

Атаклы "Зәңгәр шәл" пьесасындагы зимагурларның "Чум, чум, закон безгә нипочум" дип җырлаганын хәтерлисездер. Ә безнең җәмгыять – зимагурлар җәмгыяте, безнең дәүләт – зимагурлар дәүләте түгелдер, ләбаса?

Шуңа күрә дә мин бу мәсьәләне бүгенге көн тәртибенә кертеп, аек акыл һәм сабырлык белән фикер алышырга, туган телебезне, милли мәгарифебезне саклап калу һәм аякка бастыру өчен бергәләп гамәлләр кылырга чакырам. Без күпмилләтле республикада бер-беребезне хөрмәт итеп, дусларча килешеп яшәргә тиеш. Ә бер-береңне хөрмәт итү бер-береңнең туган телен хөрмәт итүдән башлана.

***Разил Вәлиев***

*(Разил Исмәгыйль улы Вәлиев Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, фән, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Татарстанның халык шагыйре, Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил исемендәге премияләр лауреаты, Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре)*



## «ТИК ТАТАРСТАН КЫСАЛАРЫНДА ГЫНА КОТЫЛУ МӨМКИН ТҮГЕЛ»
**(кыскатып алынды)**

... Татарстанның белем бирү киңлекләрендә хәзерге хәл чиктән тыш тискәре. Россия татарларының 1/5 өлеше рус телен үзенең туган теле дип исәпли... Өйдә аралашырлык һәм аны иркен куллана алырлык дәрәҗәдә туган телен белүчеләр Татарстандагы татарларның 1/3 өлешеннән артмый. Хәзерге көндә рус мәктәпләрендә кертелгән укыту варианты гамәлгә ашырылса (татар балаларының күбесе шунда укый) ..., тиздән бөтенләй урыслашкан татарлар хасил булыр, аларның төп аралашу теле рус теле булыр... Әгәр мөстәкыйль мәдәнияте булмаса..., Татарстан нигә кирәк, анда Казан яки Самарско-Ульяновско- Казанская (=Поволжская) губернасы да җитәрлек була...

Әгәр татар җәмгыятьчелеге тизлектә акылына утырмаса, менә шундый ахырзаманлык соңгы нәтиҗә... Татарлар бөтен дөньяда юкка чыга барган «алтынга буйсыну» моделен Россиядә дәвам итүчеләргә каршы торырга сәләтлеләр.... Бу очракта сүз бер процесс турында бара- этносларны да һәм аларның телләрен дә тулысынча бертөрле итү (унификацияләү): бүген- татарларны һәм татар телен, бераздан соң русларны һәм рус телен (глобализация векторына яраклы рәвештә аларга я инглиз, я кытай теле каршы куелачак)... Нәкъ шуның өчен дә мин Россия өчен көчле шомлану тоям, чөнки татар теленә һәм татар халкына һөҗүм – бу безнең зур Ватаныбыз колачында булачак бүтән бик авыр процессларның башы. Шуңа күрә тик бер Татарстан кысаларында гына котылу мөмкин дә түгел... Бөтен Россия күләмендә (һәм аның мәнфәгатьләре өчен), хәтта Евразия күләмендә, чын рус патриотлары белән кулга-кул тотынышып, хәрәкәт итәргә кирәк...

***Дамир Исхаков, тарих фәннәре докторы***
*https://www.business-gazeta.ru/article/366452*


VI-й выпуск школы №14 им. Великой Октябрской Революции. Алма-Ата
1941 г.


Алма-ата. Клуб „Нацмен" (быв. мечеть).

*Татарстанның халык язучысы, Габдулла Тукай һәм Гаяз Исхакый исемендәге премияләр лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рабит Мөхлис улы Батулла Алматы шәһәрендә кунакта булды. Ул мондагы милләттәшләре белән очрашулар үткәрде. Рабит Батулланың чыгышлары тыңлаучыларда онытылмаслык истәлек калдырды.*

**ВСТРЕЧА ДВУХ ВЕЛИКИХ СТАРЦЕВ**

Рабит Батулла вместе с известными деятелями местной татарской диаспоры, профессорами Грифом Хайруллиным и Рауфом Гараевым, общественным деятелем Рабином Сафаргалиевым принял участие в научно-практическом круглом столе, посвященном 90-летию видного ученого- уйгуроведа Мунира Ибрагимовича Ерзина. Круглый стол был организован в Институте востоковедения АН РК. Мероприятие открыл директор Института востоковедения Абсаттар Дербисали, основным докладчиком выступил профессор Аблет Камалов.

- Среди историков-уйгуроведов Мунир Ибрагимович занимает особое место, - отметил Аблет Камалов. - Он является «первопроходцем» целой области в уйгуроведении, связанной с историей уйгурской советской печати. «Уйгур совет матбуатинин тарихи» - так называлась его первая книга, которая была издана в 1980 г. на уйгурском языке. Дополненная и переработанная версия книги под названием «Становление и развитие уйгурской советской печати» была выпущена на русском языке в 1988 г. и сразу привлекла внимание научной общественности как первая работа, в которой прослежен процесс зарождения уйгурской печати. Большой заслугой М.Ерзина является то, что он доказал на основе анализа письменных источников, что уйгурское книгопечатание в Восточном Туркестане имеет тысячелетнюю историю. Он опровергает устоявшееся представление китайских ученых о том, что уйгуры заимствовали книгопечатание у китайцев 800 лет назад.

До сих пор ни одна книга по интеллектуальной истории уйгуров XX в. не обходится без ссылки на исследования Мунира Ерзина.

В науку он пришел после долгих лет работы в уйгурской журналистике в Восточном Туркестане, выходцем из которого он является. В 1947 г. М.Ерзин начинает свою профессиональную деятельность с редакции уйгурской «Синьцзян гезити». Позже М.Ерзин продолжил работать в Кульдже, в редакции газеты «Инкилабий Шаркий Туркестан». Следует отметить, что журналистская деятельность М.Ерзина в Восточном Туркестане привлекла внимание японской исследовательницы Наоко Мидзутани, которая опубликовала об этом статью в Токио. Журналистскую деятельность М.Ерзин продолжил и в Алма-Ате, где работал в редакции газеты «Коммунизм туги». С 1967 г. М.Ерзин работает в Секторе уйгуроведения, в котором он был единственным специалистом со знанием китайского языка; далее- в Институте языкознания и Институте уйгуроведения. Он участвовал во всех научных проектах Отдела истории, одним из которых стала коллективная монография «Краткая история уйгуров» (1990). В ней перу М.Ерзина принадлежит раздел об истории уйгуров в монгольский период.

М.Ерзин всегда живо интересовался историей своего родного татарского народа и татарских общин, разбросанных по всему миру. Историю татарской общины Восточного Туркестана на примере прошлого своей семьи М.Ерзин рассказал в книге «Тропою предков» (2005).

В исторической науке сложилось представление о том, что древние татары были монголоязычным народом, что отразилось в идее о «татаро-монгольском нашествии». Идея о монгольском происхождении древних татар вполне




соответствовало идеологическим установкам советского времени. Тогда стала популярной так называемая «булгарская теория», согласно которой современные татары являются потомками тюркоязычных булгар, создавших государство на Волге. М.Ерзин обосновал необходимость всестороннего подхода к истории татар, считая, что тюркоязычные татары Центральной Азии сыграли большую роль в происхождении и этнической истории современных татар.

Собранные в течение многих лет сведения из китайских источников по истории татар Центральной Азии М.Ерзин представил в своей монографии «Гасырлар сере. Тайны веков» (2012). Особенностью книги было многообразие рассматриваемых вопросов: от истории древних татар и средневекового уйгурского книгопечатания в Турфанском государстве до проблем татарской диаспоры Казахстана. Следующая книга «Из глубины Евразии» (2015) посвящена истории татарских общин Маньчжурии и Японии, которые оказались вне влияния Советской России и потому могли развивать свою культуру. В книге получила отражение и история древних уйгуров, с которыми тесно была связана история татар Центральной Азии. И здесь нельзя не вспомнить слова нашего известного журналиста Ядикара Сабитова, который назвал М.Ерзина мостом между татарским и уйгурским народами.

Свое девяностолетие Мунир Ибрагимович встречает с большими успехами. Достижениям в своей профессиональной жизни он во многом обязан постоянной поддержке своей семьи - супруги Гүлбану һәдә, дочерей Гульмире и Зульфие и внуков Зарифу, Данияру и Хайирниса, которые помогают ему до сих пор в его творческой работе.

В своем приветственном слове Рабит Батулла подчеркнул, что приехал отдать дань уважения, высказать слова признательности Муниру Ерзину от имени литераторов Татарстана. «У нас богатое наследие, начиная с булгарского поэта X века Кул Гали, поэта XI века Сулейман ибн Дауд ас-Саксини Сувари, поэта XVII века Кандалый, а также Мавля Колый, - отметил Рабит Батулла. - При этом у нас, у тюркских народов - казахского, татарского, уйгурского, кыргызского и узбекского народов - много общего, включая одни и те же слова, традиции, произведения. К примеру, кем был по происхождению Ак Мулла, ведь и казахи, и татары, и башкиры чтят о нем память, считая своим поэтом. Именно Ак Мулла проложил культурный мост между Казахстаном и Татарстаном, такой же мост в наши дни проложил Мунир Ерзин. Его научные труды, написанные им книги имеют международное значение, они получили высокую оценку на его исторической родине в Татарстане, заслужили благодарности Президента республики Минтимера Шаймиева, поэта и политика

Разиля Валиева, выдающегося историка, публициста Миркасыма Усманова. Лично я вижу его миссию в объединении тюркских народов. Особого уважения, восхищения заслуживает и то, что он владеет китайским языком и издал труды на китайском языке. В этом его фигура сопоставима с личностью знаменитого китаеведа Эдуарда Паркера, внесшего неоценимый вклад в мировую тюркологию. Напомню, Паркер - автор книги «Татары. История происхождения великого народа». В Китае больших высот в политической карьере достиг наш земляк Бурхан Шахиди, занимавший посты губернатора города Урумчи, председателя правительства Синьцзяна, председателя Исламской Ассоциации Китая. Но научного наследия, как Мунир абзый Ерзин, Бурхан Шахиди не оставил».

В Национальной библиотеке состоялась встреча Рабита Батуллы с представителями татарской диаспоры. Его выступление исчерпало все временные лимиты, но люди не спешили расходиться, прозаика засыпали вопросами и комплиментами, его благодарили за приезд, за интересную беседу, новую информацию и за его красивый татарский язык, чистый, богатый и грамотный. Его речь была очень содержательной (из его уст звучали даты, цифры, имена, цитаты, занимательные исторические факты, рассказы о литераторах разных эпох), гость эмоционально декламировал стихи (к слову, у него есть актерское образование) и блистал остротами.

Звучали строки из произведений Габдуллы Тукая, Марины Цветаевой, Мусы Джалиля, Евгения Евтушенко и других знаменитостей. В ходе встречи он приводил демографические данные касательно татарского народа, как в советский период, так и после распада СССР, а также отвесил поклон Льву Гумилеву, который в своем творчестве выказывал огромное уважение к тюркским народам.

Это был настоящий мастер-класс ораторского искусства и в то же время урок патриотизма. Между делом писатель задавал аудитории неожиданные вопросы и за правильные ответы, проявленную смекалку дарил памятные призы. Два часа пролетели, как один миг. Присутствующие признались, что почерпнули из встречи с Рабитом Батуллой массу нового, а для молодежи подобный лекторий стал бы ликбезом во многих вопросах.

Он уверен в себе, всецело поглощен любимым делом, им дорожат соотечественники и представители татарских диаспор многих стран, но есть проблемы, которые камнем лежат на его сердце. И главная из них - грядущее ограничение изучения татарского языка в школах лишь до двух часов в неделю. У представителей интеллигенции этому нет объяснения!

***Зухра Табаева, фото автора***



**ИСТӘЛЕКЛЕ ОЧРАШУ**

Рабит Батулла белән очрашу-искитәрлек кызыклы, тирән эчтәлекле вакыйга булды. Рабит Батулла бит – кабатланмас күпкырлы талант иясе, ул артист та, драматург та, язучы да, сценарист та, телевидениедән 800 тапкыр әкият сөйләгән әкиятче бабай да. Тынгысыз йөрәкле Батулланы татар милләтенең киләчәге, ничә еллар буе кыерсытылып, бүген юкка чыгу дәрәҗәсендәге Ана теле уйландыра. Дөнья буйлап сибелгән милләттәшләрен барлап, көнкүрешләре белән кызыксынып, кулыннан килгән барлык мөмкинчелекләрен файдаланып ярдәм итүче шәхес ул. Кая гына барса да, татар халкы аны таный, рәхмәтләрен әйтә. Мин дә изге теләкләремне белдерәм.

*Дөнья буйлап ил гизеп,*
*Татар милләтен барлап,*
*Төрле яладан аклап,*
*Саф татар телен саклый,*
*Матур ап- ак мыеклы,*
*Дан-хөрмәтка лаеклы*
*Батулла Мөхлис улы!*

*Милләтем киләчәге*
*Һәрбер әйткән сүзендә.*
*Яшәү көче балкып тора*
*Янып торган күзендә.*

*Сәяхәтче дә Бату,*
*Әкиятче дә Бату!*
*Сәясәтче дә Бату,*
*Артист та, режиссер да,*
*Үткен телле мәзәкче;*
*Татар тарихын язган*
*Нәфис телле романчы.*

*Ихлас күңелдән телим*
*Исәнлек-саулык аңа,*
*Дан-хөрмәт Батуллага!*
*Татарны татар иткән*
*Сакалын саклаганга!*

Рабит Батулла балалар өчен байтак әкиятләр язган кеше. Аның «Исемем минем Дүрткүз», «Ат өстендә бер батыр», «Алтын куллы Гөлчәһрә», «Курай уйный бер малай» һ.б.ш. әкиятләре күпләргә таныш.



Батулланың «Сөембикә кыйссасы» ни тора! Халкыбызның тарихы белән кызыксынучыларга татар тарихы дәреслеге булырга лаеклы әсәр- татар теленең бай хәзинәсе, тарихыбыздагы гүзәл образлар, мавыктыргыч маҗаралар энциклопедиясе. «Яралы бүре», «Тузга язмаган хәлләр», «Кылдан нечкә, кылычтан үткен» һ.б.ш. тарихи әсәрләре милләтебезнең горурлыгын арттыра.

2000- елларда Рабит Батулла изге китап-Коръән Кәримне тәрҗемә итү эшен башлый. Мөселманнарның изге китабындагы сүрәләрне Батулла татар телен белгән һәркем өчен дә аңлашырлык дәрәҗәдә тәрҗемә итә. Коръәннең татарча тәрҗемәсендә кулланылган, хәзерге көндә онытыла башлаган сүзләр татар әдәбиятын тагын да баета.

Рабит Батулла 70 тән артык китапларның авторы. Әлбәттә, зур казанышлар аңа җиңел генә бирелмәгән. Сәламәтлеге какшавына да, йөрәгенә берничә тапкыр операция ясатуына да карамастан, ул үзенең игелекле изге эшләрен дәвам итә.

Алматыда очрашу кичәсендә Рабит Батулла тарихи Ватаныбыз Татарстанның яңалыклары белән таныштырды, тирән эчтәлекле чыгышы белән җыйналган халыкның бар игътибарын үзенә җәлеп итте. Рабит Батулла һәм аның ышанычлы терәге-хатыны Рузия ханым мондагы милләттәшләргә китаплар бүләк иттеләр. Бу очрашу барыбызга онытылмаслык хатирә

булып калды. Рабит Батулла һәм Рузия ханымның Алматыга килүләрен оештырган Рабин Сәфәргалигә һәм Гриф Хайруллинга рәхмәтләр әйтәсе килә.

Рабит Батулланың тормышы, аның иҗат җимешләре белән танышкач, аның татар булып туып чын татарча яшәп иҗат итүенә сокланып, аның өчен горурлануымнан туган күңелемдәге изге хисләр шигъри юллар булып тезелде.



*Башыңдагы бүрегең*
*Бирмә син бирәүгә дә.*
*Туктап артка чигенмә*
*Үрләргә менгәндә дә.*

*Күпкырлы иҗатыңнан*
*Илаһи көч алып кал.*
*Гомер кояшың батмый*
*Шул Батулла булып кал!*



*Ир асылы Батудан*
*Үрнәк алырга кирәк.*
*Аның кебек изгеләр*
*Дөньяга туа сирәк.*

*Үзеңне сыныйм дисәң,*
*Батулла булып кара.*
*Чын татар булам дисәң,*
*Батулла булып кара!*

***Равил Гозәиров, Татарстан язучылар берлегенң әгъзасы***





**КҮРЕНЕКЛЕ ЯЗУЧЫ РАБИТ БАТУЛЛА**

Алматы шәһәрендә милли китапханәдә зур әдәби очрашу кичәсе булып узды.Китапханәдә китапханәчеләр «Татар әдәбияты» дип аталган китап күргәзмәсе ясаган иде. Кичәгә Алматы шәһәрендә яшәүче һәм иҗат итүче язучылар, шагыйрьләр, журналистлар, татар һәм башкорт иҗтимагый – мәдәни үзәгенең җитәкчеләре, актив әгъзаләре, кичәгә чакырылган кунаклар катнашты. Әдәби очрашу кичәсен профессор, язучы, шагыйрь, педагогика фәннәре докторы Хайруллин Гриф Тимурович ачты.Ул Рабит Батулланың күренекле язучы, миллләтпәрвәр шәхес, режиссер, артист, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясы белән бүләкләнгән. Татарстанның халык язучысы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, актив җәмәгать эшлеклесе икәнен әйтеп узды.

Бу кичәдә Рабит Батулла үзенең иҗаты белән таныштырып, бүгенге көндә җитмеш китабы, ун томлык әсәрләре басылып чыкканлыгын әйтте. Залда утыручы кешеләргә сораулар куйды.Сораугa дөрес җавап биргән залда очрашучылар зур бүләкккә Казаннан алып килгән авторның китаплары белән, дисклар белән бүләкләнделәр.Ул үзенең сорауларын татар язучыларының иҗаты, фаҗигалы язмышы белән бәйләде.Татар халык бәете Сак – Сок бәетенә тукталып үтте һәм җырлап күрсәтте.

*Мәдрәсәләрдә пыяла ишек,*
*Сак белән Сокның бәетен ишет.*
*Әнкәй орышты тимер ук өчен,*
*Әнкәй орышты бигрәк юк өчен.*
*Самовар куйды,чәйләр эчерде,*
*Эчеп бетергәч, каргап очырды.*

Сак –Сок бәетенең баланы тәрбияләүдә нинди зур әһәмияткә ия булганын әйтте. Ана баланы шул хәтле каргарга тиеш түгел, ә, киресенчә, йомшак кисәтү юнәлешендә тәрбияләргә тиеш, диде ул үзенең чыгышында. Беренче татар китабының тугызынчы гасырда язылганын әйтте. Кол Галинең 1233 елда язылган «Кыйссаи - Йосыф» китабы турында сөйләде. 14 гасырда иҗат иткән Сәиф Сараи Урта Иделнең Камышлы авылында туган, «Гөлестан бит төрки», «Ядкар - намә» китапларының авторы. Батулла шундый сәнгатьле итеп аның шигырен яттан укыды, Габдулла Тукайның иҗатына тукталды һәм аның шигырен яттан укыды.

Татар язучыларына, шагыйрьләренә хас булган илаһиятлек, фәлсәфи фикер йөртә белү, фидакарьлек, фидаилек - болар барысы да Габдулла Тукайда шагыйрь буларак тупланган, дип күрсәтте Батулла. 2012 елда Батулланың сценарие буенча куелган «Күк капусы ачылганда» - дип аталган татар күркәм фильмы Габдулла Тукайның тормыш юлын, аның иҗат юлын, аянычлы тормыш юлын, аның иҗат юлын, аянычлы мәхәббәтен, татар халкының фаҗигале язмышын сурәтли.



Режиссер булып Батулла татар җыры легендасы Әлфия Авзалованың якты истәлегенә багышлап фильмнар төшергән.Дөнья күләмендә билгеле балет артисты, балетмейстр, режиссер Рудольф Нуриевка Рабит Батулла сценарие буенча тулы метражлы документаль фильм төшерелгән.

Бу әдәби очрашуда Рабит Мөхлис улы татар әдәбиятының классик язучылар иҗатын рус әдәбияты классик язучылары иҗаты белән тыгыз бәйләде. Муса Җәлил иҗаты хакында, шагыйрь Хәсән Туфанның иҗат юлы турында сөйләде. Батулла 2000 елда Хәсән Туфанның 100 еллыгына «Туфан» исемле китапны төзеп чыгарган.

Мөлаем елмаеп, залны үзенә җәлеп итеп, тәэсирләнеп күп татар, рус шагыйрьләренең шигырьләрен яттан сөйләде.Без ниндидер олы хистә, эчке кичерешләр белән, бик нык дулкынланып язучы Рабит Батулланың чыгышын тыңладык.Чыгыш соңында язучы, галим, журналист Ерзин Мөнир Ибраһим улы үзенең чиксез рәхмәтен белдерде. «Без сезне бик еш ТНВ- планета каналы тапшыруларында күрәбез. Сез үзегез ясаган тапшыруларны кызыксынып тыңлыйбыз» - диде. Рабит Мөхлис улына зур иҗат уңышлары теләде, үзенең китабын бүләк итте.Татарстан язучылар берлегенең әгъзасе, язучы, шагыйрь Гозаиров Равиль Якуп улы шагыйрьгә ныклы сәламәтлек, бәхетле гомер, иҗади уңышлар теләп үзенең китабын бүләк итте.Без барыбыз да шушы теләкләргә кушылабыз.

Рабит Мөхлисулы һәм тормыш иптәше Рузия Раиф кызы бүләккә дип алып килгән Китапларын Алматы шәһәрендәге милли китапханәгә, татар һәм башкорт иҗтимагый – мәдәни үзәгендә урнашкан татар китапханәсенә, килгән кунакларга истәлекле язу белән бүләк итте. Барыбыз да мондый очрашулар ешрак булсын иде, дигән теләктә калабыз. Милли китапханәдә язучы Рабит Мөхлис улы һәм тормыш иптәше Рузия ханым килгән кунаклар белән белән истәлеккә фото сурәткә төштеләр.

*Олуг дәрәҗәгә җиттең*
*Зур язучы булып киттең.*
*10 томың басылып чыккан*
*Бөек шагыйрь булып киттең.*

*Җитмеш китап дөнья күргән,*
*Тормыш сине бик борчыган.*
*Дөреслекне язгансың син,*
*Башкайларың михнәт күргән.*

*Шагыйрь әйтсә, хак әйтә ул,*
*Дөреслекне ярып сала.*
*Синең шигырьләрне тыңлап,*
*Күңел хисләрдә тирбәлә.*

*Бар җиһанга исбат итеп,*
*Дөреслекне сөйләүче син.*
*Язучы син, тәнкыйтьче син,*
*Режиссер син, тарихчы син.*

*Дөреслекне язасың син*
*Күңелгә юл саласың син.*
*Сүзең үткен кылыч кебек,*
*Йөрәкләрдә каласың син!!!*

***Галиева Сания, якшәмбе мәктәбе укытучысы***

## ЭХО САБАНТУЯ

Хочется сказать несколько слов о проведенном в Алмате празднике Сабантуй-2017. Он давно перерос из национального праздника только татар и башкир в Праздник Дружбы и Добра всего народа Казахстана. Мы еще раз встретились с нашими старыми друзьями, увидели новые лица. Это радует, потому что наш общий праздник жив и будет жить. Сабантуй собирает друзей – это именно про нас.

В этом году алматинский сабантуй был особенным. Был новый статус, были применены новшества, было новое место проведения. Прежде всего, этот сабантуй проходил под эгидой объединения татарских и башкирских этнокультурных организаций в единое целое – Ассоциация «Идель» и Ассоциация татар и башкир Казахстана слились в один Казахстанский конгресс татар и башкир.

Мы уже готовились к этому сабантую в формате стадиона. Главные преимущества – это большое количество сидячих мест, удобный обзор майдана сабантуя: концертная сцена, зона национальных игр, зона спортивных состязаний, Город мастеров, фуд-корт. Был сделан пролог праздника «Дружба народов Казахстана» с участием хореографических коллективов этнокультурных центров Алматы, были изготовлены майки, бумажные кепки с логотипом праздника, изящные тантамарески.

Всё прошло замечательно! Даже дождь не смог стать помехой – зрители просто пересели на трибуне чуть выше, укрывшись под крышей стадиона, а артисты, Город мастеров и фуд-корт были защищены от дождя навесами и палатками. Единственное, было жаль, что борьба не состоялась – судьи запретили бороться на скользком от дождя борцовском ковре.

Очень хочу поблагодарить всех, кто принял участие в организации праздника сабантуй Алматы 2017. Прежде всего, это акимат города Алматы в лице акима Бауржана Байбека, заместителя акима Армана Кырыкбаева, руководителя секретариата Ассамблеи народа Казахстана по городу Алматы Назара Балгимбаева, директора КГУ «Когамдык келісім» Жанат Мурунову, Всемирный Конгресс татар и министерство культуры Республики Татарстан. Благодарю художественные коллективы этнокультурных центров Алматы за участие в прологе сабантуя.

Наверное, праздник бы не состоялся без активного участия председателя Центра гуманитарного развития «Ильдаш», депутата маслихата Алматы Нурии Ниязовой. Она «выбила» для нас бесплатно концертное звуковое оборудование мощностью 15 кВт, 20 шатров, частично концертную сцену с крышей.

Шафхат Гатаулин полностью подготовил дизайн сабантуя. Его компания DASM Group является крупнейшей группой рекламных компаний в Казахстане, Центральной Азии, на Кавказе, в Монголии и Украине. DASM Group является официальным и лицензированным партнером международных сетей WPP и Group M.














Корпорация «Раимбек» в лице управляющего партнера, члена совета директоров холдинга Сергея Полухина выставила свои соки и напитки в качестве призов не только в Алматы, но и во всех сабантуях по всему Казахстану.

Наиль Нуров, директор Дирекции 28-й Зимней Универсиады Алматы- 2017, полностью взял на себя обеспечение спортивного блока праздника, включая борцовский ковер.

Рауф Кенчинбаев взял на себя заботу над артистами из Татарстана.

Культурный центр (председатель Р.Р.Гизатуллин) организовал и провёл все народные игры.

Генеральное консульство Российской Федерации в Алматы постоянное оказывает постоянное внимание к делам татар и башкир.

И, конечно же, Рустам Агеев, владелец компании HAPPYLON, взявший на себя основную финансовую нагрузку. Он оплатил печать оформления праздника, брендированные бумажные кепки, майки и тантамарески, доставку и вывоз, сборку и разборку шатров, фонд на призы за национальные игры, сцену, гонорар артистам, оплату за электричество, ночную охрану и уборку территории на стадионе, фуд-корт, оплату гостиницы для артистов из Татарстана.

Сегодня в общественную работу татар и башкир приходят новые люди – и это замечательно, потому что вся наша жизнь - в движении. Организация таких крупных мероприятий нас сближает, делает нас сильнее, мобильнее. Мы чувствуем плечо соседа, смотрим в одну сторону, видим одну цель, стремимся к ней, получаем ожидаемый результат.

Впереди у нас новые цели. Но прежде чем мы пойдем к ним, мы должны для себя понять: где мы видим себя, наших потомков через 20, 50, 100 лет. Увидев себя на этой шкале Истории, мы точно будем знать, что мы ходим.

Большое спасибо всем участникам и организаторам прошедшего алматинского праздника Сабантуй- 2017!

Без булдырабыз! Мы можем!

***Ринат Абдулхаликов, Алматы***

***Казакъстан татарлары һәм башкортлары Конгрессы оешмаларының ижтимагый- мәдәни тормышы фотографияләрдә***






ТЕМIР ЖОЛ
ЖОЛАУШЫЛАР
ТАСЫМАЛЫ
АЛМАТЫ
КАЗАНЬ
5




Біртуар асыл ақын – Сұлтанмахм


Сұлтанмахмұт


ВЫХОД




біздің қолымызда!


АЛҒЫС ХАТ









EXIT







## БЕЗНЕҢ КАЗАХСТАН

Казахстанның мөстәкыйльлектә, ирекле рәвештә яшәүенә 26 ел тулды. Казахстан халкына, бигрәк тә казакъларга, зур шатлыклы көннәр. Котлы булсын, «Мәңгелек ил» дип атадык, мәдәният үзәге булып, халкыбыз күңел белән рухи шатлыкта эшләп, Илебез алга атлый бирсен!

Казахстанга яңача, тиешлечә әйбәт эшли торган, йомыш бирүчеләр белән яхшы бәйләнештә булган 199 эш белән тәэмин итү үзәкләре ачылган. Вакытлыча эш түгел, үзенә яраклы эш табып, урнаштыралар. Эшсез йөргәннәр булмасын дип, курсларда укытып, өйрәтеп тә эшкә кертәләр.

Семейдә эшләргә теләгәннәргә, аз вакыт эчендә йөзләгән эш урыны табылып, гаиләләре куанып сөйлиләр икән. Кем булса да- укытучымы, дәвалаүчеме, гади генә кул эшен алып баручылар да “Илебез үзгәрде” дип сөйләргә яраталар икән.Кызылордада да халык мәнфәгатен уйлап, вакытлыча булса да, кысынкылыкта яшәгәннәргә фатирлар бирелә икән.

Халык арасында дуслык, татулык арта. Украина белән дә бергәләп эшләгән 800 оешма бар икән. Монда яшәгәннәре “Без Казахстанда яшибез” дип куанып сөйлиләр.

Россиянең Сирияда булып, булышлык иткән солдатлары үз иленә исән-сау әйләнеп кайткан, дип хәбәр иттеләр. Ата-анага, гаиләсенә нинди куаныч! Россия хатыннары икенче, өченче бала тапса, аңа шатланып, билгеләп куя торган булганнар. Бездә бит андый балалар туса, күптән билгеләү генә түгел, акчалай да тиешле бүләге була.

Авыл хуҗалыгы мәсьәләсен алсак, Алматы өлкәсенә караган бер авылда асыл сыерлар күбәйтергә тырышалар. Бер сыердан 40-45 литр сөт савыла икән.Ул сөттән күпме ашамлык хәзерләп, сатырга була!

Үткән елларда бик күп бодай җыеп, чит илләргә дә җибәрдек. Киләчәктә дә экспортны арттыру планда бар. Бодайдан он, макарон, вермишель кебек һәм төрле ярмалар чыгарырга тиешлебез. Кушылып эшли торган коллективлар арта.

Казахстанда ислам абруен күтәрергә тырышалар. Халык тыныч кына күңелләнеп яши. Ислам дине илебезгә зыян китермәс дип әйтеп куялар. Хәзер бездә 2900 мәчет эшли икән.

Үз динен зурласын, чит илләргә барып, акчага кызыгып, терроризмга күңелен салып йөрмәсен дигән уй туа. Мин үзем дә, укытучы булып 30 ел эшләгәчтен, “Тәрбия юлында” исемле китабымда исламның файдалы ягын күрсәттем, намаз уку – ул гимнастика эшләү кебек, дип яздым. Мөхәммәт пәйгамбәрнең кечкенә чагыннан ук яхшы кешеләр арасында тәрбияләнеп, күп җирләргә барып, күпне күргән, әйтеп бетерә алмаслык асыл кеше булуын күрсәттем.

***Наилә Абдулкаримова, Алматы***


| ГАЗЕТА “ФИКЕР” № 1 (114) 2018 год. Электронная версия<br>Орган Казахстанского конгресса татар и башкир | |
|---|---|
| Главныйредактор<br>Г.Т.Хайруллин<br>Компьютерная верстка<br>Р.Р.Наратов | Свидетельство о постановке на учет средств массовой информации<br>№13715 от 26 июня 2013 года. Выдано Комитетом архивов Министерства культуры и информации РК |